| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>ОЛЫ МЕМИ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

29.11.2021　　　　с. Большие Мемиі　　　　№ 22

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Олы Мемиі авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Олы Меми авыл җирлеге Башкарма комитетының карарына үзгәрешләр кертү турында

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең электрон формасында күрсәтелүгә карата таләпләргә үзгәрешләр кертү турында" 2021 елның 18 сентябрендәге 1574 номерлы РФ Хөкүмәте Карары нигезендә,

Карар бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентларын раслау турында» Олы Меми авыл җирлеге Башкарма комитетының карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.16 пунктының 2.16.1 бүлегенең б) пунктчасына түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә:

«шулай ук хезмәт күрсәтүнең административ регламентында каралган очракларда, күрсәтелгән кабул итүгә бер үк вакытта язылып, мондый запрос бирү мөмкинлеге»;

1.2. 2.16 бүлекнең 2.16.1 Пунктында түбәндәге эчтәлекле "ж" һәм "з" пунктчалары өстәргә:

ж) дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында каралган вариантын билгеләү максатларында мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү вариантын билгеләү максатларында мөрәҗәгать итүчене анкеталаштыру (күрсәтелгән сорауларга җавапларның мөрәҗәгать итүчегә исемлеген һәм вариантларының тулы исемлеген күрсәтү);

з) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү вариантын күрсәтү»

2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　　　Г.А. Фомина